РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЯНУРУСОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНУРЫС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Постановление
18.12.2025

Карар
№ 22

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге башкарма комитетының бухгалтеры хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2024 елның 20 июнендәге 9 номерлы карарына үзгәрешләр керту хакында

Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлегенең башкарма комитеты карар бирә

1.Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге башкарма комитеты бухгалтеры хезмәтенә түләү шартлары турында» 20.06.2024 ел, № 9 карарына (19.06.2024 ел, N 20, 15.11.2024 ел, N 13, 30.04.2025 N 9) түбәндәге үзгәреш кертергә:

- 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бухгалтерның вазыйфаи оклады түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

Вазыйфасы	Халык саны булган муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары
	3,5 мең кешегә кадәр
Баш бухгалтер	-
Бухгалтер	29 000 рублей

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Янурыс авыл җирлеге
башкарма комитет җитәкчесе

А.Ә.Мөхәмәдиева